ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2023 ел № 22/6

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү өлкәсендә аерым Шәһәр Советы карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Шәһәр Уставының 28 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турындагы Нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасын кертү турында» 2010 елның 26 августындагы 53/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2010 ел, 1 сентябрьдәге 167-168 саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләүнең яңа системасын кертүгә юнәлдерелгән чаралар хакында» 2011 елның 27 гыйнварындагы 8/4 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2011 ел, 2 февральдәге 16-17 саннарында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2011 ел, 4 марттагы 52-56, 11 марттагы 57-63 саннарында басылган

3) Шәһәр Советының «Сәламәтлек саклау муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәтләренә түләү күләме һәм шартлары турындагы Нигезнамәне раслау хакында» 2011 елның 26 маендагы 12/12 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2011 ел, 29 июньдәге 75 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2011 ел, 10 июньдәге 90 санында басылган;

4) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы 50/5 санлы Карары белән расланган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 20 декабрендәге 22/7 номерлы Карарын, «Челнинские

известия» газетасының 2012 ел, 28 декабрьдәге 101 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 4 гыйнвардагы 1 санында басылган;

5) Шәһәр Советының «Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү системасын камилләштерү турында» 2013 елның 31 октябрендәге 27/9 номерлы Карарының 1,3,5 пунктларын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 15 ноябрьдәге 86 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 13 ноябрьдәге 85 санында басылган;

6) Шәһәр Советының «Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү турында» 28/9 номерлы Карарын, 2013 елның 19 декабрендәге «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 27 декабрьдәге 98 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2014 ел, 10 гыйнвардагы 1 санында басылган;

7) Шәһәр Советының «Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү мәсьәләләре турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/8 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2016 ел, 30 ноябрьдәге 89 санында басылган;

8) Шәһәр Советының «Муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне арттыру турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 19/5 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 27 сентябрьдәге 71 санында басылган.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев